ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры А.В. Хохоринның полиция эшчәнлеге турында 2021 елгы хисабы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры А.В. Хохоринның полиция эшчәнлеге турында 2021 елгы хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлектә «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасы кысаларында комплекслы чараларны гамәлгә ашыруны дәвам итүне.

2.2. Татарстан Республикасы гавами хакимият органнары, иҗтимагый берләшмәләр, традицион дини конфессияләр, милли-мәдәни автономияләр белән хезмәттәшлектә җәмгыятькә милли, раса, дини экстремизм һәм ксенофобия идеологиясе үтеп керүгә каршы тору өлкәсендә чаралар үткәрүне, мөмкин булган милләтара низагларны булдырмауны дәвам итүне.

2.3. Массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнарның шәхси иминлеге, аларның акчалары һәм мөлкәте саклanышы мәсьәләләрен ачыклап бирүче, хокук бозулар кылуның хокукый нәтиҗәләре һәм мөмкин булмаган дәрәҗәдәге социаль үз-үзеңне тотыш турындагы, шулай ук эчке эшләр органнары эше турында халыкта уңай фикерләр тудыручы мәгълүмат урнаштыру эшен дәвам итүне.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын гамәлгә ашыру һәм үз вакытында финанслау эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

4. Җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Хокук саклау органнары белән хезмәттәшлектә муниципаль берәмлекләр территориясендә җәмәгать тәртибен саклау һәм гражданнарның иминлеген оештыруны активлаштыруны.

4.2. Административ комиссияләр эшенең нәтиҗәлелеген арттыруны һәм җирле үзидарә органнарының административ хокук бозуларны ачыклаучы һәм тиешле беркетмәләр төзүче вазыйфаи затларының эшчәнлеген активлаштыруны.

4.3. Җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, шулай ук халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар булдыру эшен дәвам итүне.

4.4. «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын гамәлгә ашыру кысаларында муниципаль видеокүзәтү системаларын үстерүне дәвам итүне.

4.5. Укучы яшьләрнең дәрестән тыш вакытта мәшгульлеген оештыру максатларында балаларны, яшүсмерләрне һәм яшьләрне физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру чараларын күрүне.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 16 марты
№ 1364-VI ДС